**СОВЕТ ЛАИШЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

422610 г.Лаишево,
ул. Первомайская, д.39
тел: (8-84378) 2-51-51
факс: (8-84378) 2-55-55

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЛАЕШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОН СОВЕТЫ**

422610 Лаеш ш.,
Беренче май урамы, 39 нчы йорт,
тел: (8-84378) 2-51-51
факс: (8-84378) 2-55-55

**13-РС** **2019 елның 3 апреленнән**

# КАРАР

**Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы муниципаль милкенә караучы, канәгатьләнерлек булмаган хәлдәге мәдәни мирас объектларына карата ташламалы аренда түләве урнаштыру һәм аның күләме хакында Кагыйдә турында**

2003 елның 6 октябреннән № 131-ФЗ “Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында”гы Федераль законга, 2002 елның 25 июненнән №73-ФЗ “Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирасы объектлары турында”гы Федераль законга, “Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы” муниципаль берәмлеге Уставына ярашлы төстә, шулай ук мәдәни мирас объектлары булган күчемсез милек объектлары белән идарә итүнең нәтиҗәлелеген күтәрү максатыннан, Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль район Советы КАРАР БИРДЕ:

1. Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы муниципаль милкенә караучы, канәгатьләнерлек булмаган хәлдәге файдаланылмый торган мәдәни мирас объектларына карата ташламалы аренда түләве урнаштыру һәм аның күләме турындагы кушып бирелүче (кушымта) Кагыйдәне расларга.
2. Бу карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми сайтында Интернетның мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендәге http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы һәм Лаеш муниципаль районы рәсми сайтының Интернетның мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендәге http://laishevo.tatarstan.ru веб-адресы буенча бастырырга (халыкка чыгарырга).
3. Әлеге карар үтәлешенә контрольлек итүне район Советының законлылык, хокук тәртибе һәм җирле үзидарә органнары белән хезмәттәшлек итү буенча Комиссиясенә йөкләргә.

**Башлык - муниципаль район Советы**
**рәисе вазифаларын башкаручы** **Т.П.Бурганова**